| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.09.2019 ел Баулы шәһәре №265

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 маендагы 151нче номерлы карары белән расланган (2018 елның 5 сентябрендәге 323нче номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 32нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) "2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015-2021 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» дәүләт программасын раслау турында»гы 2014 елның 19 июлендә кабул ителгән №512 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 17 июнендә кабул ителгән 495нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 18 маендагы 151нче номерлы карары белән расланган (2018 елның 5 сентябрендәге 323нче номерлы, 2019 елның 15 февралендәге 32нче номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) "2015-2021 елларга Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Муниципаль программа атамасында һәм аннан соң текст буенча «2015-2021» санын «2015-2022» санына алмаштырырга;

1.2. «Паспорт программасы» бүлегенең I «Программаны финанслау күләмнәре еллар һәм чыганаклар буенча» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп бирелгән программаны финанслау күләме</td>
<td>Баулы муниципаль районы җирле бюджетыннан финанслауның гомуми күләме 232 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча (мең сум):<br><br>
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Җирле бюджет акчалары</th></tr>
<tr><td>2015</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>29</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>29</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>232</td></tr>
</table>
Искәрмә: финанслау күләме фараз характерында һәм Баулы муниципаль районының җирле бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, аңа ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td>
</tr>
</table>

1.3. V «Программаны ресурс белән тәэмин итүне нигезләү» бүлегендә беренче абзацта һәм аннан соң текст буенча «203 мең сум» санын һәм сүзләрен «232 мең сум» саннарына һәм сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Программага кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров